

Кочкурово районы Татар Умысы-Ымызы авылында vткəн жомга конне илкvлəм проект буенча капиталь ремонтланган һəм техник яктан жиһазландырылган авыл Мəдəният йортында Мəvлид əн-Нəби - Мохəммəд пəйгамбəрнен туган конен зурлап бəйрəм иттелəр. Əлеге моһим рухи, мəдəни һəм ижтимагый вакыйганын инициаторы һəм топ оештыручысы Россия моселманнары Үзəк Диния нəзарəтенен Мордовия Республикасы буенча вəкалəтле вəкиле Рафаэль-хəзрəт Манюров булды.      Дин тотучылар очен бу традицион бəйрəм, əһəмияте буенча ул Ураза һəм Корбан бəйрəмнəреннəн генə калыша. Бəйрəм бер мəйданчыкта торле миллəт һəм дин кешелəрен берлəштерде. Тантанада катнашучылар һəм мəртəбəле кунаклар арасында Мордовиянен дəvлəт һəм муниципаль хакимият органнары вə-киллəре, ижтимагый һəм дини оешмалар житəкчелəре, Ватанны саклау- чылар - махсус хəрби операциядə катнашучылар, кvрше регионнардан, шул исəптəн Татарстаннан «Алпар» этно-торкеменнəн кунаклар, шулай ук дин кардəшлəребез бар иде. Мəvлид программасы тирəн дини, мəгърифəтчелек һəм мəдəни мəгънəгə ия иде.



Чарада Коръəн укучыларны тын-ладылар. Дин əһеллəре һəм профессиональ артистлар башкаруында Мохəммəд пəйгамбəрнен тормыш юлы, шəфкатьлелеге, зирəклеге һəм югары əхлакый сыйфатларына багышланган нашидлар, традицион дастаннар һəм касыйдəлəр янгырады.

«Алпар» этно-музыкаль торкеме чыгышы бəйрəмгə аерым тосмер бирде: ижади программа милли уен коралларында башкарылган уникаль этник музыка белəн баетылды. «Алпар» этно-торкеме музыкантларынын реконструкциялəнгəн борынгы кыл-кубыз, думбыра, курай, кубыз, даф, танбур инструментлар аккомпанементы астында жырлаулары жые-лучылар очен аерым бvлəк булды.



Кунаклар һəм чарада катнашучылар бертавыштан бəй-рəмнен барлык дин тотучылар очен зур əһəмияткə ия булуын билгелəп vттелəр. Мондый очрашулар оммəтнен эчке бердəмлеген нығытып кына калмый, миллəтара һəм динара монəсəбəтлəрне гар-монияләштерvгə дə зур олеш кертə. Нəтижəдə, Россия халыкларынын бердəмлеге елында Татар Умысында vткəн Мəvлид əн-Нəби бəйрəме традицион рухи-əхлакый кыйммəтлəрнен уртаклыгын раслады: тынычлыкта, кvршелектə һəм vзара ихтирамда яшəvче торле яшьтəге, торле миллəт кешелəрен берлəштерде.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**